# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасының аерым закон актларына
үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасы Мамадыш суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында" 2010 елның 31 декабрендәге 119-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче суд участогы чикләрен тасвирлауның икенче абзацында "Малмыж," сүзен төшереп калдырырга;

2) 2 нче суд участогы чикләрен тасвирлауның икенче абзацында "Дегетле,", "Керәшен Пакшины,", "Рагозино, Сикәнәс," сүзләрен төшереп калдырырга.

**2 статья**

"Татарстан Республикасы Актаныш суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында" 2010 елның 31 декабрендәге 120-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче суд участогы чикләрен тасвирлаудан ", Чишмә" сүзен төшереп калдырырга;

2) 2 нче суд участогы чикләрен тасвирлаудан "Яңа Кормаш" сүзләрен төшереп калдырырга.

**3 статья**

"Татарстан Республикасы Биектау суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында" 2010 елның 31 декабрендәге 126-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче суд участогы чикләрен тасвирлаудан "Пермяк, Сосновка," сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 2 нче суд участогы чикләрен тасвирлауда ", Чернышевка, Чыршы һәм Шуман" сүзләрен "һәм Чернышевка" сүзләренә алмаштырырга.

**4 статья**

"Татарстан Республикасы Зеленодольск суд районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында" 2011 елның 1 августындагы 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына кушымтага (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2013, № 6 (II өлеш), 8 нче суд участогы чикләрен тасвирлаудан "Олы Ходяш,", "Мизиново," сүзләрен төшереп калдырып, үзгәреш кертергә.

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 13 гыйнвары
№ 1-ТРЗ